**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Тинчәле авыл җирлеге составына керүче Сарсаз торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар**

23.11.2023 № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Иске Тинчәле авыл җирлегенең Сарсаз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Сарсаз авылында юлларны ремонтлау өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2023 елның 23 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә, гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә 10 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны- 8 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашкан 8 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Иске Тинчәле авыл җирлеге составына керүче Сарсаз авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип таныырга.

2. «Иске Тинчәле авыл җирлегенең Сарсаз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Сарсаз авылында юлларны ремонтлау өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Сарсаз авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Иске Тинчәле авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: __________ С.Р. Хәсәнов

Иске Тинчәле авыл җирлеге
башлыгы __________________ А.З.Габайдуллин